**Хуҗиәхмәтов Ә.Н.**

# МИЛЛӘТЕБЕЗ ПЕДАГОГИКАСЫНДА ЭКОЛОГИК ТӘРБИЯ

*Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан шәһәре*

Адәм баласы үзен һәрвакыт табигатьнең бер өлеше итеп хис иткән. Табигатькә табынган, табигатьтән тормыш алган. Табигатькә сакчыл караштa булган. Бу карашлар җыелмасы бик борынгыдан безнең бабаларыбыз тормышында да гамәлдә булган. Шулай табигатькә сакчыл караган, гамәл кылган. Кешелек цивилизациясе җәмгыятьнең югарырак баскычларына күтәрелә башлагач, табигатьтән читләшә, аны санга сукмый, үзе яшәгән тирәлекне, әйләнә тирә мөхитны алга-артка карамыйча туздыра, исраф итә башлый. Хезмәт җитештерүчәнлегенең үсүе, халык саны арту, яңа табигатькә яраклаштырылмаган җитештерү технологияләре куллана башлау атмосферага, сулыкларга, җиргә, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына зур зыян китерә. Кеше үз кулы белән ясаган хаталарны аңлый башлады. Елгаларны кирегә бору дисеңме, сал агызып елга төпләрен агач белән тутыру һәм эчертү дисеңме, һавага зур күләмдә токсик матдәләр бүлеп чыгарумы, елгаларга завод-фабрика ташландыкларын агызумы, урманга барса аны пычрату, агач кисү, хайваннарның шактый төрләре юкка чыгару, авыл хуҗалыгында химик ашламаларны дөрес сакламау һ.б.лар, һ.б.лар бихисап күп "этлекләр" эшләде. Җир йөзеннән күп үсемлек һәм хайван төрләре юкка чыкты, яисә юкка чыгу алдында тора. Болар бар да кеше кулы белән табигатькә карата эшләнгән җинаятьләр. Ә бит бабаларыбыз табигатьне сакларга, аңа тормыш чыганагы буларак сакчыл, хөрмәт белән карарга кушканнар.

Хәзергесе көндә тәрбиянең шул хисаптан милли тәрбиянең дә мөһим бер юнәлеше мәктәпләрдә яшь буынны мөстәкыйль тормышка әзерләгәндә экологик тәрбия юнәлеше кулланыла башлады. Ул экологик тәрбия бирү, балаларда экологик мәдәният тәрбияләү, ягъни табигать белән килешеп, үзеңне табигатьнең бер өлеше, җан кисәге итеп карарга, табигатьтә сакчыл эш итәргә, аны хөрмәт итәргә, вә аңа карата ярату хисе тәрбияләргә.

Милләтебез борын-борыннан "туган җир", "туган туфрак" төшенчәсенә, аның байлыкларына хөрмәт тәрбияләгән, сакчыл эш итәргә кушкан. Бу халык әйтемнәрендә, мәкальләрендә чагыла. Дәресләрдә бу әйтемнәрне куллану, аларның асылына төшендерү укучыларны уйланырга мәҗбүр итә. Мәсәлән, халкыбыз урманнарның әһәмияте, аларның табигатьтә һәм кеше тормышындагы роле турында: "Урман үстер – ачлык күрмәссең", - ди. Инде урманны саклау һәм үстерү турында кисәтә һәм борчылып: "Урманга шырпы белән бармыйлар", "Агач





үлеме – балтадан". Урман кисәргә туры килгәндә дә иң кирәклесен генә, юкка сарыф итмичә генә эш итәргә куша. "Бер агач кисәрдән элек, ике агач утырт!" - дип кисәтә.

"Яшь агачны сындырма – яшь гомерең өзелер", "Агачның тамырына балта чабып, киләчәгеңне караңгылама", "Җимеш ашыйсың килсә, чәчәген өзмә", - дип һәрдаим кисәтеп тора. Мондый кисәтүләр баланы уйланырга мәҗбүр итә.

"Агач утыртканга – оныклар табыныр, агач кискәнгә – балалар каргарлар". Бу күп милләтләрнең яшәү кануны. Бабаларыбызның агачларга булган мөнәсәбәтен күрсәтә. Ул мөнәсәбәтләрнең тирән хөрмәт белән сугарылганлыгын, агачларның җаны барлыгын чагылдырган. Кеше агачлар белән сөйләшкән, алырны аңлы, җанлы, кеше сыйфатларына тиң дип санаган. Агачлардан ярдәм сораган, эш башлаганда фатиха алган.

Борынгы славян халыкларында иң хөрмәтле агач булып имән хисапланган. Ул егәрлек, көч символы саналган. Агачларның Алласы итеп кабул ителгән. Изгеләштерелгән имәнне Перун дип атаганнар. Чуваш, мукшы, латышлар имәнне шулай ук изгеләштергәннәр. Рус милләте өчен иң яраткан агач булып каен саналган. Украиннар өчен каен – "яклаучысыз кыз" - тормыш символы саналган. Кавказ халыклары – тиле наратны (тис), таджиклар – платанны (чинар), алманнар – чыршыны, греклар – кипарисны, фригийцлар – наратны, келтьлар – чыпчык җилемен (омеланы), татарлар – өянкене изге санаганнар.

Кеше тормышында агачлар зур урын биләгәннәр. Агач кешенең күләгәсе (икенче тормышы) аның тормышын саклаучы, аңа көч бирүче итеп саналган. Агач белән кешенең уртак язмыш дип кабул ителгән. Күп халыкларда баланың туган көнендә агач утырту йоласы яши. Бу агач баланың игезәге итеп саналган. Алманнар ир баланың туган көнендә алмагач, кыз бала туса – груша агачы утыртканнар. Урыслар ир бала туса ишек алдына имән, диал (тополь), кыз бала туса – каен белән нарат утыртканнар.

Безнең борынгы бабаларыбыз кабиләнең, ыруның, йортның символы итеп бай тирәк, караулы тирәк (тополь) утыртканнар, аны изгеләштергәннәр. Безнең бабайларда бай тирәккә сәлам бирү йоласы яшәгән. Караулы (хуҗасы бар) тирәккә тию (кисү, чабу, сындыру) тыелган. "Тирәгең барда, терәгең бар", - ди безнең халык. Тирәк ата-баба нигезе итеп кабул ителгән.

Аучы-марийлар агачлардан – юл, төн кунарга – рөхсәт сораганнар. Төн кунгач рәхмәт әйткәннәр. Корейцларда "изге туемнар"дагы агачларны "карамага алу" тәртибе яшәгән. Карамага алуны агачка саламнан беләзек бәйләү белән күрсәткәннәр.

Кешеләр зур имән астында яшәсәң гомернең озын булуын сиземләгәннәр: имән өлешчә үзенең көчен кешеләргә биргән. “Көч бирә” торган агач дип каен, ә “көчне ала” торган агач дип усак саналган. Усак һәм тирәк агачлары начар энергияне, чирне үзләренә алганнар, - дигән инану яши.

Озак яшәүче агачларларга еш мөрәҗәгать итәләр. Алардан сәламәтлек, байлык, уңышлы гаилә кору, бала табу сораганнар. Күп милләтләрдә агачлар үлеләрнең җаннарын кабул итү инануы яшәгән. Шул сәбәпле агачларны кисү катгый тыелган. Урысларда, инанулары буенча, мондый агачны кискән кеше акылдан шашарга, я булмаса аягын-кулын сындырырга, я булмаса үләргә тиеш була. Украиннарда җимеш агачларын төпләү тыелган, юкса бу кеше үләргә тиеш була. Белоруслар агач шартлаганын ишетсәләр, җәберләнгән кешенең җаны елауга юраганнар.

Шулай итеп гасырлар буе кешедә агачка карата сакчыл караш тәрбияләнгән. Бу тыюлар тулы бер урманнарны кисүдән саклаганнар. Моның ачык мисалын бүгенге көн тормышта адым саен күрәбез.

Бабаларыбыз агачларның гомер озынлыгын да яхшы белгәннәр:

Саз кипасы – 6 000 елга кадәр;
Имән – 2 000 елга кадәр;
Артыш – 2 000 елга кадәр;
Юкә – 1 000 елга кадәр;
Элмә – 800 елга кадәр;
Ак чыршы – 600 елга кадәр;
Нарат – 600 елга кадәр;
Кара чыршы – 500 елга кадәр;
Каен – 400 елга кадәр;
Зирек – 300 елга кадәр;
Усак – 300 елга кадәр;
Диал (тополь) – 200 елга кадәр;
Өянке – 200 елга кадәр.

Ауропада кешеләрнең туган вакытына карап бу вакытта аны нинди агач саклавы турындагы урман җәдвалы төзегәннәр. Ул борынгы грекларга да билгеле булган. Каен: 24 декабрьдән - 20 гыйнварга кадәр; миләш: 21 гыйнвардан – 17 февральгә кадәр; дардар: 18 февральдән – 17 мартка кадәр; зирек: 18 марттан – 14 апрельгә кадәр; тал: 14 апрельдән – 12 майга кадәр; дүләнә: 13 майдан – 9 июньгә кадәр; имән: 10 июньнән – 7 июльгә кадәр; очлы яфрак: 8 июльдән – 4 августка кадәр; чикләвек куагы: 5 августан – 1 сентябрьгә кадәр; йөзем агачы: 2 сентябрьдән – 29 сентябрьгә кадәр; чормавык: 30 сентябрьдән – 27 октябрьгә кадәр; балан: 28 октябрьдән – 24 ноябрьгә кадәр; аю баланы (карга миләше): 25 ноябрьдән – 22 декабрьгә кадәр. Бу җәдвалны төзүчеләр аны ай елына нигезләгәннәр: елда 364 көн, 28 көннек 13 айдан





торган. Ай елына бер тәүлек өстәлгән – ул 23 декабрь. Бу көн ел беткән, ягъни үлгән көнгә туры килгән. Бу көнне тиле нарат (тис) агачы саклаган. Менә ни өчен бу агачны үлем агачы дип атаганнар. Бу вакыт аралыгында аталган агачлар чәчәк атканнар, я булмаса зур уңыш җитештергәннәр. Милләтләрнең агачларга булган бу кыйммәтле тәҗрибәсен алга таба тәрбия процессында кулланырга иде. Моннан без, һичшиксез, фәкать отачакбыз гына.

Кошлар темасын үткәндә “Сыерчыкларга оя яса – эшең уңар”, “Кошларны кыерсытма – каргарлар”, “Кошларга таш атма – күзең сукыраер”, “Кош оясы туздырма – каргышы төшәр” - кебек үгет-нәсихәтләр аларга үзеңә булган мөнәсәбәтне булдырырга куша.

Тәрбия максатында халкыбыз тарафыннан иҗат ителгән мифны китерәбез. Ул песи дип атала.

ПЕСИ

*Бик борынгы заманда, кош-корт, җәнлекләр арасындагы татулык беткәч, песи чыпчык тоткан һәм корбанны ашарга җыенган. Чыпчык, хәленең мөшкеллеген аңлап, хәйләгә керешкән:*

*- Язмышым сиңа азык булудыр. Ярый, ашасаң ашарсың. Үлгәнче үзеңә бер үгет бирәсем килә. Син мине шулай ук битеңне-кулыңны юмый ашаячаксыңмы? Бу бит әдәпсезлек. Әдәпкә өйрәнергә кирәк.*

*- Песи, уйлап-уйлап торган да, чыпчык хаклы, дигән нәтиҗәгә килгән – кулларын, битләрен ышкырга, юарга керешкән. Ләкин авызын сөртә алмаган – авызындагы чыпчыгы комачаулаган. Песи чыпчыкны авызын юганчы гына дип куеп тормакчы булган. Ә чыпчыкка шул гына кирәк тә, песи авызыннан төшү белән, очкан да киткән.*

*- Песи үзенең алдануын бик тиз аңлап алган, ләкин инде соң булган, чыпчык – агач башында, ә ул ач калган. Шул көннән алып песиләр кулларын, битләрен ашаганнан соң юа башлаганнар.*

Менә күрдегезме әдәплелек үлемнән дә коткара икән.

Йорт хайваннарының да гомер озынлыгы билге булган безнең бабайларга:

Ат – 20 – 30 ел;
Сыер – 15 – 20 ел;
Сарык – 10 – 12 ел;
Кәҗә – 10 – 15 ел;
Йорт куяны – 5 ел;
Эт – 10 – 15 ел;
Мәче – 7 – 8 ел.

Йорт хайваннары арасында да озын гомерлеләре булганлыгы билгеле. Әйтик, 33 яшькә җитеп бозаулаган сыер һәм 21 яшькә җитеп бәрәнләгән сарыкларның булганлыгы билгеле.

Сулыкларны саклау, аларның адәм баласы тормышында әһәмиятен ассызыклап: “Төкермә коега, суын эчәрсең”. “Су кулны юа, ә суны ни юа?”. савыттагы су өсләрен һәрвакыт ябулы тотарга, чишмә яннары

чиста, пөхтә җыештырылган, агач утыртылган булуын искәргән һәм шулай эшләгән. Коеларның өсләре ябулы, кое бурасының җир өслеге өлеше балчык белән шактый биек итеп күтәртелгән булуын теләгән.

Әйтик, җир-су хайваннарын өйрәнгән вакытта: “Баканы кыерсытма, кайгыдан башың чыкмас”, “Хайваннарны кыерсытма, үзеңә килер” - үгет-нәсихәтләр балаларга хайваннарга да яхшы мөнәсәбәт булырга тиешлеген искәртәләр.

Менә безнең бабаларыбыз тормышыннан бел кызыклы факт. Сугыш елларында тукланучга кытлык кичергән халык байбакларны да иткә файдаланган. Алар югалу дәрәҗәсенә җиткәннәр. Шулай да алар мөселман авыллары тирәсендә берни дә булмагандай яши бирәләр. Ни өчен? Мөселман халкы байбакның иртән чыгып көнчыгышка карап басып алгы тәпиләре белән бит юууын мөселманның иртән Кыйблага карап намазга утыруы белән тиңләгән. Шундый изге, гыйбадәт кыла торган, “мөселман” хайванга ни кул күтәрергә җөрьят итәсең?!

Әйтик, милләтебезнең песигә булган мөнәсәбәтен генә алыйк. Йола буенча песигә үзе табынга утырганчы ук азык бирү кабул ителгән. Бу ничек тикшереп карасаң да дөрес йола. Беренчедән, песи ашарга сорап борчымаячак, икенчедән, бу чисталык билгесе. Песигә, тулаем алганда хайваннарга хөрмәт тәрбияләү йөзеннән бу гыйбарәнә китерү дә урынлы булыр.

*Безнең милләттә песиләр йоклаганда аларны борчу, уяту гөнаһ дип саналган. Шулай бервакыт песи хуҗасының чапан итәгенә ятып йоклаган имеш. Ә бу кешенең мәчеткә намазга барасы бар икән. Ул песине уятып тормыйча, чапан итәген кисеп калдырган.*

Бу хикәя белән балаларда йорт, табигать хайваннарына, киек, кошкортларга уңай караштa булырга кирәкне искәртергә тели милләтебез. Инде хәзер фән песинең кешенең нерв киренкелеген киметә, тынычландыра, арганлыкны, стрессны киметә дип раславын беләбез.

Бабаларыбыз йортта яши торган үрмәкүчләргә тимәскә куш-каннар. Үрмәкүчләрне үз максатларында да файдаланганнар. Шулай килешеп дус-тату яшәү үрмәкүч өчен дә, кеше өчен дә файдалы булган. Үрмәкүч пәрәвезен төрле чирләрдән файдаланганнар. Әгәрдә үрмәкүчнең төшкәнен күрсәң юраганының тормышка ашуын да искәрткәннәр.

Хайваннарның мондый үзенчәлекләрен әби-бабаларыбыз табигатьне җентекләп күзәтүләре нәтиҗәсендә ачыклаганнар. Алар табигатькә безгә караганда якынрак торганнар, аны яхшырак аңлаганнар дип әйтергә генә кала. Менә тагын бер мисал. Адәм баласының елан агуын бик борынгыдан файдалануы билгеле.

*Бер кеше бик каты авырып табибка бара. Табиб зур гына бүлмәнең иң түрендә утыра. Авыруның ишектән кереп өстәл янына килеп җиткәнче яхшылап күзәтә. Шуннан соң аңа ярдәм итә алмавын әйтә. Бу кеше тормыштан өмет өзеп кайтып китә. Кайтып керсә сөт чүлмәгенә агулы еланның кереп баруын күрә. Тәвәккәлләп, дөнья белән сау-*





*буллашырга уйлый һәм чүлмәктәге сөтне эчеп бетерә. Шуннан соң үлемен көтеп йөри башлый. Озакламый ул бу турыда бөтенләй оныта, шул хисаптан авыруын да. Озак вакытлар узгач, ул әлеге табибка барып үзен тикшертеп кайтырга уйлый. Ишектән килеп керүгә, табиб аны танып ала һәм сорый: “Сез елан агуын каян алдыгыз?” - ди.* Чөнки ул заманда елан агуын табу бик кыен эш булып саналган. Шуңа да карамастан аның нинди авырулардан дәва булуын кешеләр белгәннәр. Әлеге табиб та бу турыда хәбәрдәр булган. Бал кортының агуыннан, кырмыска кислотасыннан файдалануын, аның бары тик табигатькә битараф булмавы белән генә аңлатып була.

Менә бер васыятьнең эчтәлеге.

*Олы яшьтәге кеше улләр алдыннан, улларын чакыртып ала һәм әйтә: “Мин үлгәч, миннән калган мирасны алма бакчасыннан эзләрсез”, - ди. Балалары эзли-эзли бөтен бакчасын йомшартып чыгалар. Көз көне бакча бик күп итеп уңыш бирә. Алар шунда гына мирасның нәрсә икәнлеген аңлыйлар.* Әтиләре аларга бер нәрсәнең дә хезмәтсез килмәгәнлеген аңлаткан булган.

Милләтебезнең “Ашлаган җир аш китерер, ашламаган җир таш китерер”, - дигән гыйбарәсен генә алыйк. Бу җиргә нинди мөнәсәбәт булырга тиешлеккә ишарә түгелме соң.

Борынгы заманда кызны кияүгә биргәндә иң беренче яшәү өчен кирәкле булган әйберләрне бирнә итеп биргәннәр. Шушы бирнә рәтендә иң әһәмиятлесе – ат йөге белән тирес булган, ике ат йөге тирес бирелсә, бу зур бирнәле кыз булып саналган. Тирәнтен уйлый төшсәң бу чыннан да шулай. Яңа гаилә иген игеп яшәргә тиеш булган, аның уңышы җирне ашлау белән бәйле.

Милләтебездә туган туфракка карата булган изге мөнәсәбәтне генә алыйк. Чит җирләргә, яуга китүчеләр үзләре белән бер уч туфракны янчыкка салып алып киткәннәр һәм шушы туфракның аларны исәнимин туган җиргә алып кайтырына ышанганнар.

Бүгенгесе көндә яшьләребезнең үз табигатенә зыян китерүләре турында бабаларыбыз борынгыдан кисәткәннәр һәм андый эшләр белән үзләре дә шөгыльләнмәгәннәр. Хәмер белән мавыгу, очраклы җенси мөнәсәбәтләргә керү һ.б.лар начар гадәтләр тамыр җәя. Менә бик үтемле борынгы бер гыйбратле хикәя безне бу гадәтләрдән искәртә.

*Бер кеше үзенең якын дустына кунакка килә. Монда аны күңелсезлек көтә. Аңа өч шарт куялар. Ул яки бер чынаяк хәмер эчәргә, яки яшь баланы үтерергә, яки бер хатын-кыз белән зина кылырга тиеш була. Бу кеше озак уйлаганнан соң, зина кылсам, хатын-кызны кимсетәм, бала үтерү бик зур гөнаһ, ә хәмерне эчсәм үземә генә зыян дигән нәтиҗәгә килә һәм хәмерне сайлый. Хәмерне эчкәч, ул баланы да үтерә һәм теге хатын-кыз белән дә зина кыла.*

Бу гыйбрәтле хикәя безгә хәмернең кешенең аңын томалавын, хәмер эчкән кешенең намусын да, кешелеген дә югалтуын күрсәтә.